ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 24 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында” 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 11; 2010, № 12 (II өлеш); 2014, № 4; 2016, № 7 – 8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяда:
а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә, мәгълүмат системасы операторы “Интернет” челтәрендә ачык белешмәләр рәвешендәге мәгълүматны урнаштыру мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.”;
б) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:
“3. Мәгълүмат системасы концессия килешүе яисә дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү нигезендә төзелгән яисә яңартылган очракта, мәгълүмат системасы операторы функцияләре тиешле килешүдә каралган чикләрдә, күләмнәрдә һәм срокларда тиешенчә концессионер яисә хосусый партнер тарафыннан башкарыла.”;

2) 8 статьяның 2 өлешендә “төзелә” сүзләрен “төзелә, яңартыла һәм файдаланыла” сүзләренә алмаштырырга, “исәпкә алып” сүзләреннән соң “, йә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында Россия Федерациясе законнары, концессия килешүләре хакында законнар белән, Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын җәлеп итмичә генә файдаланган очракларда, башка федераль законнар нигезендә” сүзләрен өстәргә;

3) 10 статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

“2[1]. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы концессия килешүе яисә дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү нигезендә төзелгән яисә яңартылган очракта, әлеге система операторы функцияләре тиешле килешүдә каралган чикләрдә, күләмнәрдә һәм срокларда концессионер яисә хосусый партнер тарафыннан башкарыла.”;

4) 14 статьяның 1 өлешендә “төзүне” сүзеннән соң “, яңартуны” сүзен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты                                                            Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 13 октябрь
№ 71-ТРЗ